<table>
<tr><td>СОВЕТ<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН</td><td>ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ</td></tr>
</table>

РЕШЕНИЕ КАРАР

3 мая 2024г. с.Шалты № 93

Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советының 16.10.2019 № 94 «Баулы муниципаль районы «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 19.12.2022 № 521-ФЗ Федераль закон һәм Баулы шәһәр прокуратурасының 14.03.2024 № 02-08-02/24 протесты нигезендә Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советының 16.10.2019 № 94 «Баулы муниципаль районы «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау турында» карарына (27.03.2020 № 108, 22.06.2020 № 117, 17.12.2021 № 28, 13.07.2022 № 42, 07.12.2023 № 81 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

5 статьяда:

66 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- бюджет йөкләмәләрен кабул итәләр һәм аңа җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә элек кабул ителгән бюджет йөкләмәләренә үзгәрешләр кертәләр;»

түбәндәге эчтәлектәге 72 абзац белән тулыландырырга:

«- муниципаль контрактлар, Бюджет кодексы нигезләмәләрендә һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы башка федераль законнарда

каралган очракларда расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары гамәлдә булу срогы чикләреннән тыш мондый муниципаль контрактлар, башка килешүләр буенча йөкләмәләрне үтәүне күздә тоткан башка килешүләр төзелә. Муниципаль контрактлар, башка килешүләр төзү өчен билгеләнгән күрсәтелгән Нигезләмәләр элек төзелгән муниципаль контрактларга, башка килешүләргә үзгәрешләр керткәндә дә кулланыла.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артымнан калдырам.

Шалты авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе З.Х. Фаткуллин